Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының егерме сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

19 ноябрь, 2019 ел № 231

Питрәч муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Питрәч муниципаль районы бюджетыннан субвенцияләр бирү кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 нче маддәсе нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Питрәч муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Питрәч муниципаль районы бюджетыннан субвенцияләр бирү кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге карар нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап, шулай ук алдагы елларга бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының икътисади үсеш, бюджет, салымнар һәм финанслар мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

СОВЕТ
ПЕСТРЕЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов

Питрәч муниципаль районы
Советы карары белән расланды
19 ноябрь, 2019 ел № 231

Питрәч муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Питрәч муниципаль районы бюджетыннан субвенцияләр бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетыннан (алга таба – Район) авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен субвенцияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру максатларында район җирлекләре бюджетларына бирелә.

3. Район җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетыннан Район бюджетына бирелә торган субвенция тора.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып район башкарма комитеты тора.

5. Район җирлеге бюджетына субвенция күләме «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 11 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Законга 1 нче кушымта нигезендә, хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлек бюджетына муниципаль район бюджетыннан субвенция күләмен билгеләү методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләрне бүлү тиешле финанс елына һәм план чорына район бюджеты турында район Советы карары беләнраслана.

7. Субвенция тиешле финанс елына һәм план чорына Район бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм район башкарма комитетына билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Район җирлекләре бюджетларына бирелә.

8. Субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны тормышка ашыру өчен район җирлекләре бюджетларына бирелә:

- хезмәткә түләү фондына тиешле түләүләрне дә кертеп, хәрби-учет хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү;
- биналарны арендалау өчен түләү;
- элемтә хезмәтләре өчен түләү;
- транспорт хезмәтләре өчен түләү;

• командировка чыгымнары;

• коммуналь хезмәтләр өчен түләү;

• җиһаз, инвентарь, оргтехника, элемтә чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү.

9. Субвенцияләрне тоту Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнарының (алга таба – Казначылык) шәхси счетлары аша башкарыла.

10. Район башкарма комитеты Казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң җиде эш көне эчендә Казначылыкка субвенцияләр исәбеннән Район җирлекләре бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза тапшыра.

11. Район җирлекләренең җирле үзидарә органнары хисап чорыннан соң килүче айның 5 нче числосыннан да соңга калмыйча Район башкарма комитетына финанс тәэминаты чыганагы субвенция булган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән килешү буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча җирлекләрнең бюджетлары чыгымнары турында хисап тапшыралар.

12. Район башкарма комитетына тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык район җирлекләренең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә район бюджеты керемендә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына билгеләнмәгән субвенцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Район бюджеты керемендә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын закон нигезендә Район башкарма комитеты һәм районның финанс бюджет палатасы контрольдә тота.